ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗАИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

25.12.2020 г. Заинск № 606

**«Халыкка күрсәтелә торган мунча хезмәтләренә тарифлар турында» 2019 елның 28 июнендәге 337 номерлы Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Халыкны мунча хезмәтләре белән тәэмин итү максатларында, Зәй муниципаль районы Уставының 45 статьясына таянып, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты

**карар бирә:**

1. «Халыкка күрсәтелә торган мунча хезмәтләренә тарифлар турында» 2019 елның 28 июнендәге 337 номерлы Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты карарының (2019 елның 30 декабрендәге 691 номерлы карар нигезендә кертелгән үзгәреш белән) 1 кушымтасына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1 "2019 елның 1 июленнән халыкка мунча хезмәтләре күрсәткән өчен кертелә торган тарифлар" 1 кушымтасында:

а) 2.4., 2.6., 2.7. пунктларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 2.4. | «Хаммам» номеры | сум | 2 кешегә 700,00 | |
| 2.6. | «Балалар» номеры | сум | 850,00 | 5 кешедән артканда+ һәр кешегә өстәмә 50 шәр сум |
| 2.7. | «Яшьләр» номеры | сум | 850,00 | 5 кешедән артканда+ һәр кешегә өстәмә 50 шәр сум |

2. Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының оештыру бүлегенә әлеге карарны Зәй муниципаль районының http://zainsk.tatarstan.ru рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының http://pravo.tatarstan.ru рәсми порталында урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң 2011 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

4. Карарның үтәлешен контрольдә тотуны Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисадый үсеш, сәнәгать, сәүдә, эшмәкәрлеккә ярдәм буенча урынбасары М.И. Захаровага йөкләргә.

**Башкарма комитет**
**җитәкчесе** **Э.Э. Галиев**

Юрист

А.Н. Симашева
8(85558) 3 41 33